ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «22» октября 2019 г.** **№ 130**

**Арча муниципаль районының муниципаль вазыйфалар биләүче затлары һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле булган беркетмә чаралары, хезмәт командировкаларына бәйле рәвештә алынган бүләкләрнең бәясен билгеләү максатында бәяләү комиссиясе төзү турында**

Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле булган беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү турында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2019 елның 19 сентябрендәге 74 номерлы карары белән расланган Нигезләгә яраклаштырып, бүләкләрнең бәясен билгеләү максатларында, Карар бирәм:

1. Арча муниципаль районының бәяләү комиссиясен төзергә.

2. Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле булган беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә алынган бүләкләрне бәяләү комиссиясе турындагы Нигезләмәне (№1 кушымта) һәм әлеге комиссия составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Арча муниципаль район башлыгының 2014 елның 7 мартындагы 46 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль район башлыгы урынбасары Г.Ф.Гариповка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы И.Г.Нуриев

Арча муниципаль районы
башлыгының 2019 елның
"22" октябрь
130 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Бәяләү комиссиясе турында**
**Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Бәяләү комиссиясе (алга таба-Комиссия) Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле булган беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә алынган һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына тапшырылган бүләкләрнең бәясен билгеләү максатыннан оештырыла.

## 2. Комиссия эшчәнлеген оештыру

2.1.Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.2.Комиссия рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра. Комиссия рәисе булмаган очракта, аның бурычлары комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

2.3.Комиссия сәркатибе бүләкне бәяләү өчен кирәкле барлык документларны әзерли, комиссия әгъзаларын утырышка чакыруны тәэмин итә.

2.4.Комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә. Утырышлар комиссия әгъзаларының 50% тан артыгы катнашканда хокуклы санала.

2.5.Бәяләү барышында бәяләнә торган бүләкнең (бәяләү объекты) исемлеге төзелә, анда аның җентекле тасвирламасы һәм аерым билгеләре (саны, күләме, авырлыгы, төсе һ.б.) күрсәтелә. Бәяләү бүләкне базар бәясе буенча шундый ук товар белән чагыштыру юлы белән башкарыла (кирәк булган очракта конвертация бүләкне бәяләү көнендәге курс буенча башкарыла).

Шундый ук товарны сайлаганда, бәяләү объекты кебек үк шул ук җитештерүче тарафыннан һәм шул ук илдә җитештерелгән товарга өстенлек бирелә. Бәяләнә торган объектның бәясенә шундый ук товардан аерылып торган (тузуны, комплектацияне һ.б. исәпкә алып) төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

2.6.Бүләк тарихи яисә мәдәни кыйммәткә ия булганда яки бәяләү аның сирәклеге аркасында кыенлашканда, бәяләү өчен тиешле профильдәге югары квалификацияле белгечләр җәлеп ителә ала.

2.7.Экспертларны җәлеп итү һәм башка оештыру мәсьәләләре буенча комиссия карары, утырышта катнашкан комиссиянең күпчелек әгъзалары аның өчен тавыш биргәндә кабул ителгән дип санала. Тавыш бирү тигез дәрәҗәдә тәмамланганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

2.8.Комиссия тарафыннан бәяләү барышында утырыш беркетмәсе алып барыла. Бүләкне бәяләү нәтиҗәләре Комиссия бәяләмәсе белән рәсмиләштерелә, ул җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затлар тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләкләрне кабул итү-тапшыру актына теркәлә.

*Арча муниципаль районы*
*башлыгының 2019 елның*
*“22” октябрь*
*130 номерлы карарына*
*2 нче кушымта*

**Бәяләү комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Гарифҗанов Рамил Илгиз улы | -Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе (килешү буенча); |
| Нурмиева Люция Илдар кызы | - Арча муниципаль районы Контроль-хисап палатасы аудиторы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Гыйззәтова Миләүшә Алис кызы | -Башкарма комитет аппаратының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлегенең баш белгече, комиссия сәркатибе (килешү буенча); |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Таһиров Айнур Мулланур улы | - район Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе; |
| Митина Ольга Геннадиевна | - Арча район Советының юридик мәсьәләләр буенча бүлеге баш белгече; |
| Игнатов Илфак Илдар улы | - милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы җитәкчесе (килешү буенча). |